КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 август г.Казань № 708

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 март, 157 нче, 2017 ел, 8 декабрь, 961 нче; 2018 ел, 5 апрель, 208 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1284 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында»;

2 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тәрбиягә алган гаилә төзегән һәм «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткән, стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданны тәрбияләүне гамәлгә ашырган гражданга айлык акчалата түләү билгеләргә:»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Тәрбиягә алган гаилә төзегән һәм юридик хокуклы өлкән яшьтәге грражданны тәрбияләүне гамәлгә ашыручы гражданга айлык акчалата түләү бирү буенча чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

4[1], 5 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.1 пунктының икенче абзацында «2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булу срогы» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин